Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Югары Чура авыл җирлеге башлыгы урынбасары

# КАРАРЫ

«12» ноябрь, 2025 ел № 2

**Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Кече Чура авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1 2025 елның 24 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Кече Чура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Кече Чура авылының клуб бинасында үткәрергә: Кече Чура авылы, Мәктәп ур., 2 й.

2 2025 елның 24 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Кече Чура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Кече Чура авылының клуб бинасында үткәрергә: Кече Чура авылы, Мәктәп ур., 2 й.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2026 елда Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлеге Кече Чура торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- урамнарны яктырту җайланмасы;

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;

- мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр)булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

6. Югары Чура авылы башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы урынбасары: А.Н.Афанасьев